ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
27.02.2024

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 524

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 63 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче барлык гражданнарның һәр баскыч гомуми белем алу хокукын тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибен кушымтада каралганча расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештырырга.
3. Балаларны исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы органнарның, учреждениеләрнең һәм оешмаларның барлык җитәкчеләренә үз вәкаләтләре кысаларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә һәм мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыруда ярдәм тәкъдим итәргә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтәләр бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары- Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

ТР ЗМР Башкарма комитетының
2024 елның 27 февралендәге
524 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе(алга таба текст буенча - Тәртип) Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә төп белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларның еллык персональ исәбен гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Конституциясе, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 63 статьясындагы 5 өлеше, 64 статьясындагы 3 өлеше нигезендә һәм гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга конституциячел хокукларын үтәү максатларында эшләнгән.

1.3. Тәртип Зеленодольск муниципаль районы территориясендә балаларны исәпкә алуда катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре һәм оешмалары белән берлектә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыруны билгели.

1. 4. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче (даими яки вакытлыча) яки килүче балалар, яшәү (булу) урыны буенча теркәлүгә карамастан, белем алуга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, түбәндәге яшь чикләрендә исәпкә алынырга тиеш:

түбәндәге чик 2 айлык балалар; югарыдагы чик 18 яшькә кадәрге балалар, шулай ук гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 18 яшьтән өлкәнрәкләр.

1. 5. Мәҗбүри гомуми белем алмаган балаларны ачыклау һәм исәпкә алу, гамәлдәге законнар нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үзара хезмәттәшлеге кысаларында кызыксынган затлар һәм оешмалар белән берлектә башкарыла.

1.6. Мәгариф учреждениеләренең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләре һәм органнары белән балаларны исәпкә алу буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру эшен Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсе алып бара.

1.7. Балаларны исәпкә алу Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге учреждениеләре, оешмалары һәм структур бүлекчәләре белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла:

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләре ;
- Зеленодольск муниципаль районындагы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге;
- «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ
- Зеленодольск муниципаль районы Эчке эшләр министрлыгы бүлеге;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау эшләре комиссиясе ;

1. 8.Әлеге Тәртип нигезендә, балаларны исәпкә алу буенча мәгълүмат 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Персональ мәгълүматлар турында»гы Федераль закон таләпләренә туры китереп җыелырга, тапшырылырга, сакланылырга һәм кулланылырга тиеш.

**2. Исәпкә алынган мәгълүматны формалаштыру**

2.1. Балаларны исәпкә алу Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләрендә укытылырга тиешле балалар турында Интернет-телекоммуникация челтәрендә «ЭДС» АИС һәм «ТРда электрон белем бирү» Бердәм электрон мәгълүмат банкын формалаштыру юлы белән башкарыла (алга таба тексты буенча - Мәгълүмат банкы ).

2.2. Мәгълүмат банкын формалаштырганда гражданнарның үз ризалыгы белән, ә балигъ булмаган балаларга карата аларның ата - аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән бирелгән персональ мәгълүматлары кулланыла. Гражданнарның персональ мәгълүматларын исәпкә алу «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Банкны формалаштыру чыганаклары түбәндәгеләр:

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул итүгә дәгъва итүче һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә укырга алынучы балаларның электрон мәгълүмат банкы - «ЭДС» АИС ;
- «ТРда электрон белем» ИС (электрон журнал).

2.4. Исәпкә алу мәгълүматларын формалаштырганда, Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсе Зеленодольск муниципаль районы учреждениеләре һәм оешмаларыннан, структур бүлекчәләреннән алынган мәгълүматны игътибарга ала.

2.4.1. «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белешмәләре:

- балалар турында, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма әлеге территориядә яшәүче, 6 яшьтә һәм 6 ай булган һәм агымдагы елда (рәсми мөрәҗәгать буенча) беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында
- Зеленодольск муниципаль районы территориясенә 2 айдан 18 яшькә кадәрге яңа килгән балалар турында (бирү срогы рәсми мөрәҗәгать буенча )

2.4.2. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан бирелә торган белешмәләр:

- 2 айдан 7 яшькә кадәрге , шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укуларын тәмамлаучы һәм агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә балалар турында, мәгълүмат бирү срогы ел саен 01 сентябрьгә, 01 мартка (1нче кушымта формасы буенча);
- белем бирү баскычлары һәм белем алу формалары буенча укучылар саны турында, мәгълүмат бирү срогы ел саен 01 сентябрьгә, 01 мартка (2 нче кушымта);
- тәрбияләнүчеләр , укучылар саны турында гомуми җыелма мәгълүмат, мәгълүмат бирү срогы ел саен 01 сентябрьгә, 01 мартка (3нче кушымта).
- җитди булмаган сәбәпләр аркасында укырга йөрмәгән яки системалы рәвештә дәресләр калдырган укучылар турында, мәгълүмат бирү срогы ай саен 1 нче числога (4 нче кушымта);
- балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан белем алу формасын гаиләдә белем алу һәм үзбелем формасында сайлавы турында, мәгълүмат бирү срогы ел саен 1 сентябрьгә (5 нче кушымта).

2.4.3. Зеленодольск муниципаль районында Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бүлеге тарафыннан бирелә торган белешмәләр:

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән Бердәм муниципаль мәгълүмат банкында теркәлгән балалар турында.

2.4.4. Зеленодольск муниципаль районы Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча бүлекчәсе белешмәләре:

- хөкем ителгән һәм иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче 18 яшькә кадәрге балалар турында,
- ябык типтагы махсус уку йортларында булган балалар турында.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.4.3-2.4.4 п. санап кителгән балалар турындагы белешмәләр, балалар турындагы персональ мәгълүматлары булган исемлекләр белән рәсмиләштерелә.

2.6. Әлеге Тәртипнең 2.5 п. күрсәтелгән мәгълүматлар Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсе белән хезмәттәшлек итүче оешма җитәкчеләре тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла.

**3. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан**

**билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештыру.**

3.1. Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсе:

3.1.1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче 2 айдан 18 яшькә кадәрге балаларны исәпкә алуны оештыру эшен координацияли.

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укырга хокуклы балалар саны турында белешмәләрне, мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләреннән алу юлы белән, мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алуны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, автомат мәгълүмат системасы аша ЭДС (алга таба -«ЭДС» АИС ) гамәлгә ашыра,

3.1.3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә кабул итү өчен исәпкә куелган балалар саны, шулай ук агымдагы уку елында (актуаль ихтыяҗ) һәм аннан соңгы елларда (кичектерелгән ихтыяҗ) учреждениедә урын бирүгә мохтаҗ балалар саны турында объектив мәгълүмат алу максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсе Зеленодольск муниципаль районының барлык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә исәпкә куелган балалар саны турында мәгълүмат туплаучы «ДОУ» АИС автоматлаштырылган мәгълүмат системасын (электрон чират) куллана.

3.1.4. Исәпкә алу мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны кабул итү процедурасының "ачыклыгын" тәэмин итү, гражданнарның мәктәпкәчә белем бирү, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны карау һәм тәрбияләү ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеле бер датага учреждениеләрдә кирәкле һәм җитәрлек урыннарны тәэмин итүне планлаштырганда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә бала хокукларын бозудан саклау максатларында гамәлгә ашырыла. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә урын мондый урынга ихтыяҗ турында гаризалар керү чираты тәртибендә бирелә. Федераль законнарда аерым категория гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә чираттан тыш һәм беренче чиратта урыннар белән тәэмин итү хокуклары билгеләнә.

3.1.5. Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алуның төрле формаларында: оешмада һәм оешмадан тыш (гаилә белеме һәм үзбелем бирү формасында) укучы балаларның, шулай ук башка белем бирү учреждениеләренә күчерергә мохтаҗ балаларның исәп-хисабын формалаштыра.

3.1.6. Балаларны күчерү (яңа яшәү урынына күченү, белем бирү траекториясен ачыклауга яки башка шартлар белән бәйле) бер белем бирү учреждениесеннән буш урыннары булган башка белем бирү учреждениесенә мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем алырга тиешле һәм белем бирү учреждениесендә урын бирелүгә мохтаҗ әлеге баланы исәпкә алуга кире кайтармыйча һәм аны чиратка алуга кире кайтармыйча башкарыла. Элек бала укыган белем бирү учреждениесе белән мәгариф мөнәсәбәтләре, аның әти-әнисе (законлы вәкилләре) инициативасы буенча, белем алучыларны белем бирү программасын үзләштерүне дәвам итү өчен башка учреждениегә күчерү нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясындагы 2 өлешендәге 1 пунктында каралганча, белем бирү учреждениесендә урын бирүгә мохтаҗ балаларны исәпкә алмыйча, күчерү тәртибендә туктатыла.

Баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) бер белем бирү учреждениесендә укуны туктату турында хәл итсәләр, әмма баланы күчерү тәртибендә кабул итү өчен буш урыннары булган белем бирү учреждениесен тапмасалар, укучы белем бирү учреждениесеннән чыгарыла, ә ата-ана (законлы вәкилләр) “Россия

Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 4 өлеше нигезендә мәктәпкәчә белем алуны дәвам итү өчен баланы урнаштыру мәсьәләсен хәл итүне сорап Зеленодольск муниципаль районы мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать итәләр, ул әлеге баланы мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укыту өчен белем бирү учреждениесенә урын бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә ала.

3.1.7. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формаларын исәпкә ала.

3.1.8. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) мәктәпкәчә белем алу формасын гаилә белеме формасында сайлаганда, ата-аналар (законлы вәкилләре) бу хакта «ЭДС» АИС аша Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсенә хәбәр итә. Әлеге балалар мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә урын бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә алынырга тиеш түгел һәм электрон чираттан чыгарыла.

3.1.9. Балаларның мәктәпкәчә белемне гаиләдә белем алу формасында алуын тәэмин итүче балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) түләү алмыйча методик, психологик-педагогик, диагностик һәм консультатив ярдәм алу хокукына ия, шул исәптән, әгәр аларда тиешле консультация үзәкләре төзелгән булса, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм гомуми белем бирү оешмаларында. Ярдәмнең мондый төрләрен күрсәтүне тәэмин итү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.1.10. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыра.

3.1.11. 3.1.2-3.1.8 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны анализлау нәтиҗәләре буенчаЗеленодольск муниципаль районының конкрет территорияләренә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрен беркетү турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары проектын эшли.

3.1.12. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу формасын гаилә белеме һәм үзбелем алу формасында сайлаганда, ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсенә хәбәр итә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан балаларның белем алу формаларын сайлау турында мәгълүмат әлеге карарга кушымтада каралганча таблицага кертелә (2 нче кушымта).

3.1.2. Гомуми белем алмаган балаларны мәгариф учреждениесендә урнаштыру буенча чаралар күрә.

3.3. Белем бирү учреждениесе:

3.3.1. Әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә, учреждениедә тәрбияләнүчеләрне һәм укучыларны, аларның яшәү урынына (теркәлүгә) бәйсез рәвештә, агымдагы исәпкә алуны оештыра һәм гамәлгә ашыра һәм Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсенә белешмәләр бирә.

3.3.2. Җитди булмаган сәбәпләр аркасында белем бирү учреждениесенә дәресләргә йөрмәгән яки системалы рәвештә дәресләрне калдырган укучыларны исәпкә ала.

3.3.3. Балаларының белем алуына комачаулаучы һәм (яки) балаларын тәрбияләү һәм укыту буенча үз бурычларын тиешенчә үтәмәүче гаиләләр ачыкланган очракта:

- балигъ булмаганнарны укытуны оештыру өчен ата-аналар (законлы вәкилләре) белән үзара хезмәттәшлек итү буенча кичекмәстән чаралар күрә;

- гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә йогынты чаралары күрү өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау эшләре буенча комиссиясенә хәбәр итә;

-Зеленодольск муниципаль районы Мәгариф идарәсенә күрсәтелгән балалар өчен укытуны оештыру буенча ачыкланган балалар һәм кабул ителгән чаралары (белем бирү учреждениесе, кабул итү датасы, сыйныфы, уку формасы) турында хәбәр итә.

3.3.4. Гамәлдәге законнар нигезендә балаларның агымдагы исәпкә алуы буенча Зеленодольск муниципаль районы мәгариф идарәсенә җибәрелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җавап тоталар.

3.3.5. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле 2 айдан 18 яшькә кадәрге балаларны исәпкә алу системасын камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү хокукына ия.

1 нче кушымта

2 айдан 7 яшькә кадәрге , шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укуларын тәмамлаучы һәм агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә балалар турында тиешле белешмәләр

| 2 айдан 18 яшькә кадәр ачыкланганнарның ФИАт.и. | Туу датасы | 1 нче сыйныфка, б/бакчасына (яки мәктәпнең классына, б/бакчасына ) планлаштырылган керү елы | Кайсы мәктәптә, б/б укытуны планлаштыра (кайда укый, тәрбияләнә) | Ата-аналарның ФИАт.и. | 0-18 яшьтән ачыкланган баланың теркәлү адресы | 0-18 яшьтән ачыкланган баланың теркәлү адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

2 нче кушымта

Белем бирү баскычлары буенча укучыларның саны һәм белем алу формалары турында белешмәләр

| 0-18 яшьтән ачыкланган баланың ФИАт.и. | Белем бирү формасы һәм белем алу формасы | Туу датасы | 1 нче сыйныфка, б/бакчасына (яки мәктәпнең классына, б/бакчасына ) планлаштырылган керү елы | Кайсы мәктәптә, б/б укытуны планлаштыра (кайда укый, тәрбияләнә) | Ата-аналарның ФИАт.и. | 7-18 яшьтән ачыкланган баланың теркәлү адресы | 7-18 яшьтән ачыкланган баланың теркәлү адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

3 нче кушымта

Мәгариф оешмаларында белем баскычы буенча тәрбияләнүчеләр, укучылар саны турында җыелма мәгълүмат

| № | Атамасы | Саны |
|---|---|---|
| 1 | Мәгълүмат банктында балаларның гомуми саны | |
| 2 | Мәгълүмат банктыннан киткәннәр саны (сәбәбе) | |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Мәгълүмат банкына килгәннәр  саны (сәбәп) | |
| 4 | Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләр саны | |
| 5 | 1-11 сыйныфларда укучылар саны | |
| 6 | Инвалид балалар саны | |
| 7 | Хисап датасына 1 нче сыйныфка керүчеләр саны | |
| 8 | Хисап датасына чыгарылыш сыйныф укучылары саны | |

4 нче  кушымта

Җитди булмаган сәбәпләр аркасында уку дәресләренә йөрмәгән яки системалы рәвештә дәресләрне калдырган укучылар турында белешмәләр

| № | Баланың Ф.И.Ат.и. | Туу датасы | Гомуми белем бирү оешмасы, сыйныф | Яшәү (тору) урыны буенча теркәү |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

5 нче  кушымта

Ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларның гаилә белеме һәм үзбелем бирү формасында белем алу формасын сайлавы турында мәгълүмат

| № | Белем бирү формасы һәм белем алу формасы | Ата-ананың (законлы вәкиленең) ФИАт.и. | Укучыларның ФИАт.и. | Укучыларның туган көне | Балигъ булмаган белем алган гомуми белем бирү учреждениесе исеме | Агымдагы уку елында арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен сайланган гомуми белем бирү учреждениесе исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |